**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Күл Черкене авылы гражданнар җыены карары**

21 март 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Күл Черкене авылы гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Күл Черкене авылында гражданнары җыенының 2023 елның 16 ноябрендәге 1нче номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:.

“2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- коймалар төзү, төзекләндерү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны тоту, җәйге вакытта территорияне кисү, (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр алу, Күл Черкене авылында килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү));

- урам яктырту җайланмасы;

-янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

-су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.”.

2. Җыен нәтиҗәләрен Күл Черкене авыл җирлегенең Күл Черкене авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Күл Черкене авыл җирлеге башлыгы __________ М.К. Истиев

Халык җыены секретаре __________ И.Р. Гибадуллина